# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасы Аксубай районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре турында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 23 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Аксубай районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасын әлеге Законга кушымта нигезендә расларга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 31 декабре
№ 134-ТРЗ

"Татарстан Республикасы
Аксубай районы буенча
Татарстан Республикасы җәмәгать
судьяларының суд участоклары чикләре турында"
Татарстан Республикасы Законына
кушымта

**Татарстан Республикасы Аксубай районы буенча Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд участоклары чикләре тасвирламасы**

**1 нче суд участогы**

1 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Аксубай муниципаль районының Аксубай шәһәр тибындагы поселогы, Карасу, Кәкрекүл, "МЮД", Яңа Кармәт, Иске Кармәт, Сөнчәле, Трудолюбово һәм Шәрбән авыл җирлекләре.

**2 нче суд участогы**

2 нче суд участогы чигенә түбәндәге муниципаль берәмлекләр территорияләре керә: Аксубай муниципаль районының Беловка, Емелькино, Яңа Аксубай, Яңа Ибрай, Саурыш, Иске Ибрай, Иске Илтерәк, Иске Кыязлы, Иске Татар Әдәмсуы, Иске Тимошкино, Иске Үзи һәм Урмандәй авыл җирлекләре.